**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Ташкичү авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

Кече Урыссу ав.

№ 13 23 ноябрь 2017 ел

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2017 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум нәтиҗәләрен теркәү турында**

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»гы № 67-ФЗ санлы Федераль законның 73 маддәсендәге 5 пункты, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында"гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законының 60 маддәсендәге 3 пункты нигезендә, Ташкичү авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2017 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум нәтиҗәләре турында»гы 45санлы карарын теркәргә.

2.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең әлеге карарын түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Кече Урыссу ав. авылы, Совет урамы, 21а нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru; Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында теркәргә http://jutaza.tatarstan.ru.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы: Р.К.Вәлиев.